
# Татарча сөйләшәбез



## Дидактическое пособие для использования в режимных моментах

Без ашыйбыз тәмле аш,
Тәмле аш, тәмле аш.

Без ашыйбыз тәмле ботка,
Тәмле бо … е
ботка.





# ЯЛ МИНУТЛАРЫ

Аю йөри урманда,
Тәмле бал эзли анда.
Йөри торгач арый ул,
Ял итәргә уйлый ул.



Мияу,мияу,пескәем,
Бигрәк матур
төскәең!
Кил әле,кил яныма,
Сөт салам
савытыңа.

Мә су, мә су-
Бит, кулыңны ю,
Чиста су, чиста
су –
Ю,ю,ю.



elenaranko.ucoz.ru

Туп –туп,
Зур туп.
Сикер-сикер,
Зур туп.

Туп –туп,
Кечкенә туп.
Сикер –сикер,
Кечекенә туп.



# Бармак уены

Бу бармак - бабай,
Бу бармак - әби,
Бу бармак - әти,
Бу бармак - әни,
Бу бармак  - нәни бәби,
Аның исеме  - Чәнти!



elenaranko.ucoz.ru

# Физминутка



**Кояш, чык, кояш, чык,**
**Тәти кашык бирермен,**
**Майлы ботка бирермен,**
**Тәти кашык базарда,**
**Майлы ботка казанда!**

MyShared



**Әйлән-бәйлән уены**

**Әллә-лә, әллә-лә, карусель әйләнә,**
**Матур курчак әйләнә,**
**Зур –зур аю әйләнә,**
**Кечкенә куян әйләнә.**



## Бала йоклатканда

**Йокла кызым, йокла кызым,**
**Йокла, кызым, йом күзең.**
**Үсеп матур кыз булсаң соң,**
**Кияү табарсың үзең.**

